

Июнь башында ук Темников районы «Ишейки» агрофирмасында жимолость-зелпе жыюга керешәчәкләр; карт утырт малары 3 гектар мейданда урнаштырылган. Агрофирма директоры А.С. Лисин сvзләренә караганда, бу сезонда жиләкләр кvп булыр дип котелә.      - Куаклар шактый vсте, - ди ул. - Унай һава торышы булганда, уныш узган елгыдан ике тапкыр артыграк булыр дип уйлыйм.
Агрофирмада жиләкләрнен һәм алма бакчасынын югары ундырышлылыгы турында алдан ук уйлаганнар. Чәчәк ата башлауга тагын 3 гаилә токлетура-шмель сатып алганнар һәм остәмә рәвештә барлык мәйданда 6 умарта оясы урнаштырганнар. Май башыннан биредә тамчылы су сибv системасы кертелде. Һәм бу да зур уныш нигезе. Бер vк вакытта анын аша торле жиләк-жимеш (жимолость, карлыган, кура жиләге, ежевикалар), шулай ук алмагач бакчалары тукландырылачак. Карлыган гомбә авыруларыннан эшкәртелгән. Ул жимолостьтән сон олгерә. Аннан - малина һәм ежевика.
Язгы кыр эшләренә ап- рельнен оченче декадасында керештеләр. Туклану зонасын арттыру очен аларны утырттылар, куаклар белән рәтләрне чvп-чардан чистарттылар. Болар белән Т.П.Севостьянова житәкче легендә 5 кешедән торган бригада шогыльләнде. Бу коллектив Темников, П.Канаков, Ишейка авыллары хатын-кызларыннан оешкан; биредә алар бер- ничә ел эшлиләр инде.
Агрофирманын барлык эшләре зур ачык мәйданнарда уздырылуга карамастан, кеше- ләр саклагыч битлекләрдә һәм перчаткаларда, бер-берсеннән тиешле ераклыкта; коронавирус инфекциясе йоктырудан барлык саклык чараларын vтәп эшлиләр. Конгә оч тапкыр инвентарьны махсус техника ярдәмендә эшкәртәләр.
Жимолостьнен унышын жыюда, директор сvзләренчә, 35тән 40ка кадәр кеше катнашачак.
*Рэсемдэ: Т.П.Севостьянова бригадасы эшли*